| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
|---|---|
| ***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*** | ***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*** |
| ***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | ***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

19 декабрь 2008 ел № 2-30

**«Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Буа шәһәр прокурорының 2008елның 19 ноябрендәге № 01-09-08 номерлы күрсәтмәсен карап, Буа шәһәр Советы карар кылды:

I. 2008 елның 24 июнендәге 1-27 номерлы Буа шәһәр Советы карары белән расланган Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Буа шәһәрендә муниципаль хезмәт - хезмәт шартнамәсе (контракты) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырыла торган гражданнарның һөнәри эшчәнлеге.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәр өчен салым түләүче вәкаләтләрен аның исеменнән яллаучы вәкилен (эш бирүче) гамәлгә ашыра. Буа шәһәре башлыгы, Буа шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе яллаучының (эш бирүчеләрнең) вәкилләре булып тора.»

2) 4 бүлекнең аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү буенча квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең төп хокуклары һәм бурычлары».

3) 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктча өстәргә.:

«Муниципаль хезмәткәрнең төп хокуклары һәм төп бурычлары «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьялары, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 11 статьялары, муниципаль берәмлек уставының 81 статьясы белән билгеләнә.

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган чикләүләрне үтәргә тиеш».

4) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1. Муниципаль хезмәткә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясында күрсәтелгән йөкләмәләр булмаганда, муниципаль хезмәткә 18 яшькә җиткән гражданнар муниципаль хезмәткә муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр качканда квалификация таләпләренә туры килә ала.

5) 6 бүлекнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы нигезендә муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасының өч елга 1 тапкыр туры килүен билгеләү максатларында уздырыла.

6) 7 нче «Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификация имтиханы» бүлеген төшереп калдырырга.

7) 8нче «Муниципаль хезмәткәр өчен гарантияләр» бүлеген 7 нче бүлек дип санарга.

8) 9 нчы «Муниципаль хезмәт стажы» бүлеген 8 нче бүлек дип санарга һәм түбәндәге радакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәт стажына «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә даими нигездә эшләү чорлары кертелә».

21. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү һәм билгеләү тәртибе «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә билгеләнә.».

9) 10 нчы «Муниципаль хезмәткәрне бүләкләү» бүлеген 9нчы «Муниципаль хезмәткәрне бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы» бүлеге дип санарга.

10) 9 бүлекне киләсе эчтәлекле 25.1 пункты белән тулыландырырга:

«25.1. Үзенә йөкләнгән хезмәт бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен түбәндәге дисциплинар түләтүләр дә җайга салынырга мөмкин: кисәтү, катгый кисәтү, муниципаль хезмәттән тиешле нигезләрдә эштән азат итү. Дисциплинар кисәтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә».

11) түбәндәге эчтәлекле 10 бүлек белән тулыландырырга:

« 10 бүлек. Муниципаль хезмәткәрнең эш вакыты һәм ял вакыты»

26. Муниципаль хезмәткәрләрнең эш вакыты хезмәт законнары нигезендә җайга салына.

Еллык түләүле төп отпускны һәм тиешле елларны эшләгән өчен өстәмә ялны бирү тәртибе һәм шартлары, шулай ук акчалата эчтәлеге сакланмаган ял «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы белән билгеләнә.»

12) 11 бүлекнең 26 пунктын 11 бүлекнең 27 пункты, 12 бүлекнең 27 пунктын 12 бүлекнең 28 пункты дип санарга.

II. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгы Р.Х. Әбүзәров